КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 20 июль г.Казань № 870

2019 – 2028 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2028 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасын раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1265 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 24 ноябрь, 1056 нчы; 2021 ел, 23 ноябрь, 1111 нче; 2022 ел, 18 май, 460 нчы; 2022 ел, 29 октябрь, 1151 нче, 2023 ел, 17 февраль, 151 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2019 – 2028 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Төбәк программасы паспортында:

«Төбәк программасының максатчан индикаторлары» юлында «4 560,6» һәм «2 417,9» саннарын тиешенчә «4 566,7» һәм «2 424,0» саннарына алмаштырырга;

«Төбәк программасын финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Төбәк программасын финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Төбәк программасы түбәндәгеләр исәбеннән финанслана:<br>газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлау хезмәтләренә тарифларга махсус өстәмәләр кулланудан алынган акча,<br>Бердәм газлаштыру операторы акчасы,<br>«Газпром» гавами акционерлык җәмгыяте акчасы.<br>Төбәк программасын финанслауның гомуми күләме 24 398,164 млн. сум тәшкил итә, шул исәптән: |

| | |
|---|---|
| | газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлау хезмәтләренә тарифларга махсус өстәмәләр кулланудан алынган акча, гомуми суммасы 15 585,099 млн. сум, шул исәптән:<br><br>2019 ел – 499,264 млн.сум;<br>2020 ел – 632,41 млн.сум;<br>2021 ел – 621,944 млн.сум;<br>2022 ел - 1 057,244 млн. сум;<br>2023 ел - 1 889,17 млн. сум;<br>2024 ел - 1 955,214 млн.сум;<br>2025 ел - 2 071,865 млн.сум;<br>2026 ел - 2 175,419 млн.сум;<br>2027 ел - 2 284,17 млн. сум;<br>2028 ел - 2 398,398 млн. сум;<br>Газлаштырып бетерү программасы буенча газлаштыруның бердәм операторы акчасының гомуми суммасы 5 332,865 млн. сум, шул исәптән:<br>2021 ел – 80,0 млн.сум;<br>2022 ел - 1 430,606 млн.сум;<br>2023 ел - 2 822,259 млн.сум;<br>2024 ел - 1 000,0 млн. сум;<br>Татарстан Республикасын газ белән тәэмин итүне үстерү һәм газлаштыру программасы буенча газлаштыруның бердәм операторы акчасы гомуми суммада 2 383,6 млн. сум, шул исәптән:<br>2023 ел – 82,2 млн.сум;<br>2024 ел – 119,2 млн.сум;<br>2025 ел – 776,6 млн.сум.<br>2026 ел - 1 072,6 млн. сум;<br>2027 ел - 333,0 млн. сум;<br>Татарстан Республикасын газ белән тәэмин итүне үстерү һәм газлаштыру программасы буенча «Газпром» акционерлык җәмгыяте акчасы гомуми суммада 1 096,6 млн. сум, шул исәптән:<br>2022 ел – 193,7 млн.сум;<br>2023 ел – 224,5 млн.сум;<br>2024 ел – 30,9 млн.сум;<br>2025 ел – 323,8 млн.сум.<br>2026 ел - 323,8 млн. сум»; |

I бүлекнең сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төбәк программасын гамәлгә ашыру 2019 - 2028 елларга Татарстан Республикасын газлаштыру чаралары планы, төп максатчан күрсәткечләр буенча чараларның җыелма планы, газлаштырып бетерү җыелма план-графигы, газлаштырып бетерүнең объектлар буенча план-графигы, синхронлаштыру план-

графигы, аңа 1 нче, 2 нче, 3 нче, 4 нче, 5 нче кушымталар нигезендә һәм 2022 - 2025 еллар чорына Татарстан Республикасын газ белән тәэмин итүне үстерү һәм газлаштыру программасы нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

III бүлекнең уникенче абзацында «башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

VI бүлекнең унберенче абзацында «республика дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

Төбәк программасының VII бүлегендә:

беренче абзацта «21 361,406» саннарын «24 398,164» саннарына алмаштырырга;

икенче абзацта «15 547,075» саннарын «15 585,099» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «4 717,731» саннарын «7 716,465» саннарына алмаштырырга;

VIII бүлекнең җиденче абзацында «башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

XI бүлектә:

исемендә «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

беренче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

Төбәк программасына 3 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Төбәк программасына 4 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Төбәк программасына 5 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин